УДК 372.881.1

*Г.К. Закирова*

# ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ) ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СТУДЕНТЛАРНЫҢ ҺӨНӘРИ КОМПЕТЕНТЛЫГЫН ФОРМАЛАШТЫРУ ФАКТОРЫ БУЛАРАК ТЕКСТ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

В статье рассматриваются теоретико-методологические основы работы с текстами, которые содержат профессиональную терминологию, на занятиях по родному (татарскому) языку со студентами Казанского национального исследовательского технического университета имени А.Н. Туполева. Целью исследования является комплексный анализ профессионально-ориентированного подхода в процессе обучения татарскому языку будущих инженеров авиационной отрасли. В статье выявляются лингводидактические методы обучения авиационной терминологии, предлагаются виды упражнений и заданий для работы с профессионально ориентированными текстами на татарском языке, определяются критерии отбора учебных материалов. Тщательный анализ и структуризация изучаемого материала по авиационной терминологии создают условия для студентов в освоении видов речевой деятельности, включая чтение и перевод литературы по специальности. Статья адресована исследователям в области методики преподавания языков, преподавателям высшей школы, аспирантам и магистрантам.

**Ключевые слова:** уроки родного языка, профессиональная компетентность, авиационная терминология, профессиональные тексты, методика обучения языку

The article discusses theoretical and practical aspects of working with professionally oriented texts in native (Tatar) classes language at the Kazan Aviation Institute. The aim of the study is a comprehensive analysis of the professionally oriented approach to the process of teaching the Tatar language to future engineers in the aviation industry. The linguistic and didactic features of aviation terminology are revealed, a typology of exercises for working with professionally oriented texts in the Tatar language is proposed, and criteria for selecting educational materials are determined. The article is addressed to researchers in the field of language teaching methods, higher school teachers, graduate students and undergraduates.

**Keywords:** native language lessons, professional competence, aviation terminology, professional texts, language teaching methods

Югары белем бирүнең хәзерге парадигмасы белемгә юнәлтелгән модельдән компетентлы модельгә күчү белән характерлана, шуңа күрә бу үзенчәлек студентларның белемендә, Федераль дәүләт белем бирү стандартларында да тулы чагыла. Студентларны тел компетентлыгына әзерләү, һөнәри белем һәм күнекмәләргә өйрәтүдән тыш, авиация белгечләренең һөнәри компетентлыгын формалаштыруда мөһим роль уйный. Е.В. Баженов фикеренчә, «гражданлык

авиациясендә профессиональ лексика формалашкан, бу өлкәгә караган процесслар һәм күренешләр дә әлеге лексиканы тәшкил итә» [1: 89]. Шул ук вакытта, студентларның һөнәри компетентлыкларын үстерүдә татар теленә өйрәтү, аерым алганда, әлеге белгечлекнең һөнәри бурычларын туган тел аша хәл итү өчен, тел чараларыннан нәтиҗәле файдаланырга өйрәтү максаты куела.

А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты авиатөзелеш һәм аэрокосмос тармаклары өчен инженер кадрлар әзерләүнең әйдәп баручы үзәге булып тора. Бу уку йортында студентларны тел компетентлыгына әзерләүгә зур игътибар бирелә.

Фәнни-методик әдәбиятта авиация инженерларының һөнәри компетентлыгын формалаштыру процессында туган тел (татар теле) ресурсларын куллану мәсьәләсе җитәрлек яктыртылмаган. Авиация өлкәсендә белем алучы студентларны рус теленә яки башка чит телләргә өйрәтү методикасы җентекле өйрәнелгән [1; 4; 5; 6; 8; 11]. Татар теленә өйрәтү методикасына караган хезмәтләр булса да [3; 8; 9; 10], һөнәри компетентлыкны татар телендә өйрәтүгә багышланган фәнни хезмәтләр әлегә кадәр юк. Шуңа күрә бу мәсьәлә – татар теленә өйрәтүдә актуаль проблемаларның берсе. Тикшеренүнең актуальлеге, бер яктан, авиациянең һөнәри белем өлкәсе буларак чагыштырмача яшь булуы белән билгеләнә. Шуңа күрә аның үсеше, һичшиксез, һөнәри терминологияне дә үстерүне таләп итә. Татар телендә авиация терминологиясе бөтенләй өйрәнелмәгән. Шуңа күрә авиация өлкәсенә караган терминология булдыру, аны сүзлек итеп чыгару татар теленең киләчәктәге перспектив бурычларының берсе булып тора. Әлеге мәкалә татар телендә авиация өлкәсенә караган профессиональ текстлар белән эшләүнең теоретик нигезләрен һәм практик алымнарын тәкъдим итү максатыннан язылды.

Фәнни әдәбиятта «һөнәри компетентлык» төшенчәсе турында төрле фикерләр яшәп килә. О.Н. Лебеденко һөнәри компетентлыкны «һөнәри эшчәнлекнең уңышын тәэмин итә торган теоретик белемнәр, практик күнекмәләр, һөнәри әһәмияткә ия кыйммәт ориентацияләре һәм шәхес сыйфатларын үз эченә алган белгечнең интегратив сыйфаты» [4: 7] дип карый. Димәк, тел өйрәтү һөнәри компетентлыкта аралашу чарасы гына түгел, ә профессиональ фикерләү, махсус белемнәрне тапшыру, техник документацияне язу чарасы да булып тора.

Авиация һөнәрен үзләштерүче студентларга туган телне укыту процессында барлыкка килгән түбәндәге мөһим компонентларны аерып күрсәтергә кирәк: 1) лингвистик компонент (профессиональ аралашу өчен җитәрлек дәрәҗәдә тел белеме системасын белү); 2) дискурсив компонент (төрле стильләргә караган текстларны аңларга өйрәтү); 3) терминологик компонент (һөнәрнең махсус лексикасын һәм төшенчәләрен белү); 4) стратегик компонент (конкрет һөнәри бурычларны хәл итү өчен төрле тел чараларын сайлый белү).

Авиация өлкәсенә караган һөнәри текстлар самолёт конструкциясе һәм аның хәрәкәт җайланмалары аппаратлары, борт электроникасы, идарә итү системалары һәм навигацияләр, самолётлар төзү технологиясе, проектлау, сынаулар, җитештерү һәм очкычларны эксплуатацияләү аппаратлары, аэродромнарны эксплуатацияләү, коткару җиһазлары, аэродинамика нигезләре, метеорология, аэрофотога төшерү, самолёт һәм вертолётларны хәрби максатларда куллану, һава һөҗүменә каршы элементлар һәм ракетага каршы оборона терминнарын үз эченә ала. Шулай ук һава хәрәкәте белән идарә итү терминологиясе булган, йөк һәм пассажирларны һава транспортында ташуны оештыру һәм очышларның куркынычсызлыгы турында текстлар да татар телен укытуны оештыруда мөһим роль уйныйлар.

Татарстан Республикасындагы тел вазгыяте шартларында студентларны туган телгә (татар теленә) өйрәтү югары белем бирү системасында аерым урын алып тора. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, һөнәри әзерлек процессында туган телне куллану күп кенә мөһим функцияләр үти [3: 5]. Туган тел – фикерләү коралы, шуңа күрә студент аңында һөнәри төшенчәләр туган телгә таянып формалаша. Махсус терминологияне өйрәнгәндә, терминның мәгънәсенә туган тел призмасы аша төшенсәң, аның мәгънәсе тирәнрәк ачыла. Бу – когнитив функция.

Татарстанда авиация тармагына караган лексиканың үз үсеш тарихы бар. Студентларны әлеге терминнар кергән текстлар белән таныштыру аларның һөнәри һәм милли-мәдәни фикерләү үсешен тәэмин итә.

Һөнәри текстлар телгә өйрәтүнең төп компоненты булып тора. Текстларны сайлап алганда, студентларның навигация, метеорология, очкычларны эксплуатацияләү, һава хәрәкәте белән идарә итү кебек дисциплиналардан алган белемнәрен куллану күздә тотыла. Авиация белгечлекләре өчен туган тел (татар теле) дәресләрендә кулланылган һөнәри текстларның түбәндәге төрләрен аерып күрсәтергә мөмкин: 1) фәнни-техник текстлар белән эшләү (авиация системаларының төзелеше һәм эш принциплары тасвирламасы, техник документация, инструкцияләр). Текстларның әлеге төре терминнарның еш кулланылуы, схема һәм сызымнар булу белән характерлана; 2) публицистик характердагы текстлар белән эшләү (татар телендә чыккан журналлардан һәм газеталардан алынган мәкаләләр, авиация тармагында да эшләүчеләр белән интервьюлар, предприятиеләрдән репортажлар). Бу текстлар студентларны тармакның актуаль проблемалары белән таныштырырга мөмкинлек бирә һәм бер үк вакытта һөнәри юнәлешле сөйләм белән эшләү күнекмәләрен үстерә; 3) норматив текстлар белән эшләү (куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре, регламентлар, стандартлар). Мондый текстлар белән эшләү студентларда күрсәтмәләрне төгәл үтәү өчен җаваплылык формалаштыра; 4) документаль текстлар белән эшләү (татар телендә эшлекле язышу, киңәшмә протоколлары). Әлеге жанр Татарстан

Республикасы дәүләт телләрендә эш алып баруны үстерү ягыннан әһәмиятле.

Профессиональ текстлар ярдәмендә уку-укытуны оештырганда, авиация терминологиясенең лингвистик үзенчәлекләрен игътибарга алу яхшы нәтиҗәләр бирә. Авиация терминологиясенең үзенчәлекләре татар телендәге уку-укыту материалларын әзерләгәндә, укыту әсбапларын эшләгәндә дә исәпкә алынырга тиеш. Билгеле булганча, бу терминнар – интернациональ сүзләр. Татар телендәге авиация терминнарының шактый өлеше, рус телендәге кебек үк, Европа телләреннән (беренче чиратта, инглиз һәм француз телләреннән) алынган. Мәсәлән, «авиация», «фюзеляж», «шасси», «элерон» терминнары интернациональ характерга ия. Бу үзенчәлек студентлар өчен билгеле бер өстенлекләр тудыра, әмма шул ук вакытта татар телендәге алынмаларның орфографик һәм фонетик яраклашу мәсьәләләренә игътибарлы булуны сорый.

Терминологик системада синонимик рәтләрнең булуы төрки нигезле сүзләрне сайлап алуга этәрә. Мәсәлән, татар телендә «самолёт» төшенчәсен билгеләү өчен «аэроплан» алынмасын да, татарча «очкыч», «самолёт» тәңгәллекләрен дә кулланырга мөмкин. Бу – укытучыга студентларда, контекстка һәм коммуникатив ситуациягә бәйле рәвештә, термин сайлауга аңлы мөнәсәбәт формалаштырырга ярдәм итә.

Авиация терминологиясендә синтаксик ысул белән ясалган терминнар киң таралган: «реактив двигатель», «газ турбинасы», «очыш хәвефсезлеге системасы». Мондый катлаулы номинатив берәмлекләр белән эшләү терминның эчке формасын анализлауны, төп компонентны аерып алуны һәм термин ясалу модельләрен эшләүне үз эченә алган махсус методика таләп итә.

Туган тел дәресләрен оештырганда һөнәри текстларны сайлап алуда аерым критерийлар бар. Бу текстлар студентларның әзерлек дәрәҗәсенә туры килергә тиеш. Текст артык гади дә, артык катлаулы да булырга тиеш түгел. Шулай ук чын профессиональ аралашуны чагылдырган татарча текстларга өстенлек бирелә. Текстта авиация тармагына хас терминнар һәм терминологик тезмәләрнең булуы зарур. Текстның эчтәлеге студентка мәгълүмат биреп кенә калмыйча, профессиональ дөньяга караш, һөнәргә мөнәсәбәт формалаштырырга да ярдәм итәргә, сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләрен үстерү өчен (уку, сөйләү, тыңлап аңлау, язу) нигез бирергә тиеш.

Галимнәр туган тел дәресләрендә профессиональ текст белән эшләү методикасының төп өч этабын аерып күрсәтәләр: текст алды, текст һәм тексттан соңгы этап. Һәр этапның үз максаты һәм биремнәр системасы бар [5: 3; 6: 27; 7: 16].

Текстка кадәрге этапта текст белән эшләү өчен мотивацион нигез булдыру, терминологик һәм мәгънәви кыенлыкларны ачыклау эше башкарыла. Бу этапта түбәндәге эш төрләре нәтиҗәле: 1) лексик анализга таянып, төп терминнарны аңлату эше; 2) текстның эчтәлеген

текстның исеме, иллюстратив материал, төп сүзләр аша фаразлау; 3) проблема буенча булган белемнәрне актуальләштерү.

Текстның эчтәлеге белән турыдан-туры танышу һәм аның эчтәлеген өйрәнү текст этабын тәшкил итә. Бу этапта эшнең бары тик укуга һәм тәрҗемә итүгә кайтып калмавы мөһим. Студентлар текстны укып, аның планын яисә тезисларын төзиләр, төп терминнарны аерып күрсәтәләр, игътибарны таблица, схемаларны өйрәнүгә юнәлтәләр.

Алынган мәгълүматны сөйләм эшчәнлеге төрләрендә куллану күнекмәләрен үстерү – тексттан соң эшләнелә торган этап. Бу этапта текстта очраган терминнарны кабатлау; күтәрелгән проблемалар буенча дискуссия үткәрү; текст нигезендә үз фикереңне әйтү (хәбәр, доклад, аннотация); текст фрагментларын татар теленнән рус теленә һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү эше башкарыла.

Профессиональ текстлар белән эшләгәндә студентларны төрле сүзлекләрдән файдаланырга өйрәтү мөһим. Һөнәри терминологияне үзләштерүнең уңышы күп очракта белешмә әдәбият белән мөстәкыйль эшли белүгә бәйле.

Татар теле дәресләрендә икетелле сүзлекләрне (татар-рус, рус-татар), шулай ук авиация терминнарының махсуслаштырылган тармак сүзлекләрен куллану максатка ярашлы. Рус телендә авиация терминнары сүзлеге булса да [2], кызганычка каршы, татар телендә мондый төр сүзлек әлегә кадәр төзелмәгән. Шуңа күрә текст белән эшләү дәверендә, индивидуаль терминологик сүзлек-минимум алып бару нәтиҗәле алым булып тора. Студент әлеге сүзлекчәгә терминның тәрҗемәсен, аңлатмасын һәм кулланылу үзенчәлекләре турында комментарийларны терки, яңа терминнар кертә бара.

Теоретик анализ һәм эксперименталь тикшеренү нәтиҗәләрен гомумиләштереп, туган телне (татар телен) укыту процессын оештыруда түбәндәге методик киңәшләрне бирергә мөмкин: 1) терминологияне өйрәтүдә дәвамчанлыкны тәэмин итәргә кирәк. Терминнар махсус дисциплиналарны өйрәнү мантыйгына туры китереп сайланырга тиеш. Тел дәресләре тематикасын профессиональ модульләр эчтәлеге белән координацияләргә кирәк; 2) төрле жанрлардагы профессиональ текстларны куллану сорала. Техник документацияне, норматив актларны, вакытлы матбугаттагы язмаларны да кертеп, профессиональ коммуникациянең реаль ситуацияләрен чагылдыра торган текстларга өстенлек бирү зарур; 3) студентлар термин ясаучы модельләр белән системалы рәвештә эшләргә тиеш. Терминнар ясалуның продуктив ысулларын (бигрәк тә синтаксик ысулны – күп компонентлы тезмәләрне) аңлау терминологик запасны мөстәкыйль рәвештә киңәйтү өчен нигез булып тора; 4) профессиональ текстлар белән эшләүне сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә кулланырга кирәк. Текстларны үзләштерүдән тел материалын язма профессиональ аралашуда продуктив куллануга күчешне тәэмин итәргә кирәк; 5) татар телендә профессиональ текстлар җыентыгын, әзерлек юнәлешләре буенча терминологик минимум-

нарны, мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр системасын үз эченә алган методик әсбаплар белән эшләү нәтиҗәле булачак.

Әлеге мәкаләдә ясалган комплекслы анализдан чыгып, татар теле дәресләрендә һөнәри текстлар белән максатчан эшләү А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты студентларының һөнәри компетентлыгын формалаштыруда отышлы чара булып тора. Шулай итеп, авиация терминологиясенең лингводидактик үзенчәлекләрен исәпкә алган һәм текст белән этаплап эшләү һәм терминологик күнегүләр системасын үз эченә алган методика эксперименталь укыту барышында үзенең нәтиҗәлелеген исбатлады.

Киләчәктә авиация белгечлекләре өчен татар теленнән электрон белем бирү ресурсларын эшләү, ике яки өч телле (татар-рус-инглиз) авиация терминнары сүзлеген төзү, һөнәри лексиканы системалаштыру алдагы бурычларыбыз булып кала.

## Әдәбият


1. *Баженов Е. В.* Специальная лексика и терминообразование в сфере организации воздушного движения в гражданской авиации в русском и английском языках // Litera. 2019. № 3. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/spetsialnaya-leksika-i-terminoobrazovanie-v-sfere-organizatsii-vozdushnogo-dvizheniya-v-grazhdanskoy-aviatsii-v-russkom-i-angliyskom (мөрәҗәгать итү көне: 27.05.2026).

2. *Девнина Е.Н.* Большой англо-русский и русско-английский авиационный словарь / под ред. акад. И.И. Павловца. М.: Живой язык, 2011. 512 с.

3. *Денмухаметова Э.Н., Фатхуллова К.С.* Татарский язык в системе общего образования // Современные проблемы науки и образования. 2021. № 2. URL: https://science-education.ru/ru/article/view?id=30713 (мөрәҗәгать итү көне: 27.05.2026).

4. *Лебеденко О.Н.* Особенности работы с профессионально-ориентированными текстами при обучении иностранному языку в неязыковом вузе // Электронный научно-методический журнал Омского ГАУ. 2020. № 4 (23) октябрь-декабрь. URL: http://e-journal.omgau.ru/images/issues/2020/4/00886.pdf. – ISSN 2413-4066

5. *Мартынова Н.А.* Особенности работы с профессионально-ориентированными текстами при преподавании иностранного языка в образовательных организациях МВД России // Филологический аспект: международный научно-практический журнал. Сер.: Методика преподавания языка и литературы. 2025. № 01 (30). URL: https://scipress.ru/fam/articles/osobennosti-raboty-s-professionalno-orientirovannymi-tekstami-pri-prepodavanii-inostrannogo-yazyka-v-obrazovatelnykh-organizatsiyakh-mvd-rossii.html (мөрәҗәгать итү көне: 28.02.2025)

6. *Орлова Л. Г., Корнилова Е. С.* Развитие навыков чтения текстов на иностранном языке у студентов технических специальностей // Научные проблемы водного транспорта. 2016. № 47. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/razvitie-navykov-chteniya-tekstov-na-inostrannom-yazyke-u-studentov-tehnicheskih-spetsialnostey (мөрәҗәгать итү көне: 27.05.2026).

7. *Сафиуллина Ф.С.* Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. Казан: ТаРих, 2001. 432 б.

*8. Сергеева Н.Н.* Профессионально ориентированные задания как средство обучения иностранному языку профессиональной сферы // Язык и культура. 2023. № 61. С. 272–288.

9. *Фатхуллова К.С.* Система обучения татарской диалогической и монологической речи. Казань: РИЦ «Школа», 2002. 188 с.

10. *Харисов Ф.Ф.* Научные основы обучения татарскому языку как неродному. Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 302 с.

11. *Шлямова А.А.* Педагогические условия языковой подготовки в авиационном вузе // Инновационная наука. 2016. № 1–2 (13). URL: https://cyberleninka.ru/article/n/pedagogicheskie-usloviya-yazykovoy-podgotovki-v-aviatsionnom-vuze (мөрәҗәгать итү көне: 27.05.2026).

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Закирова Гөлназ Камил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университетының Техника көллияте укытучысы*

***Закирова Гульназ Камилевна,***
*кандидат филологических наук, преподаватель Технического колледжа Казанского национального исследовательского технического университета имени А.Н. Туполева*
*gulnaz80zak@mail.ru*